**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АЛЕКСЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ**
**"АЕРЫМ ПРЕДМЕТЛАР ТИРӘНТЕН ӨЙРӘНЕЛӘ ТОРГАН**
**2НЧЕ АЛЕКСЕЕВСК УРТА ГОМУМИ БЕЛЕМ БИРУ МӘКТӘБЕ"**
**МУНИЦИПАЛЬ БЮДЖЕТ ГОМУМИ БЕЛЕМ УЧРЕЖДЕНИЯСЕ**

| **«КАРАЛДЫ»** | **«КИЛЕШЕНДЕ»** | **«РАСЛАНДЫ»** |
| --- | --- | --- |
| Методик берләшмә җитәкчесе<br>___________И.Х.Замалиева<br>МБ утырышы беркетмәсе<br>№1 «25» август 2016 ел | Директор урынбасары<br>________Л.Р.Ягудина<br><br>«27» август 2016 ел | Мәктәп директоры<br>__________Л.Н.Липлянина<br>Педагогик совет беркетмәсе<br>**233** нче номерлы боерык белән гамәлгә кертелде.<br>31 нче август 2016 ел |

Татар теле һәм әдәбияты укытучысы
Сөнгатуллина Флфра Сафуат кызының
2 «В» сыйныфы өчен әдәби укудан
эш программасы

Педагогик киңәшмә
Утырышында каралды.
Беркетмә №1
31 август 2016 ел

**2016 – 2017 уку елы**

## I.Укыту предметын үзләштерүнең планлаштырылган нәтиҗәләре

Сыйныф: 2 “В”
Укытучы: Сунгатуллина Флюра Сафуатовна
Уку планы буенча
Әдәби уку:68
Атнага: 2 сәг.
Уку тизлеген тикшерү:1

Дәреслек: Р.З. Хәйдәрова, Н.Г. Галиева, Г.М.Әхмәтҗанова ”Күңелле татар теле” Казан “Татармультфильм” нәшрияты, 2013 ел.

Программа түбәндәге документлар нигезендә төзелде:

1. Программа: Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы. Урта (тулы) гомуми белем бирү мәктәбендә рус телле балаларга татар телен коммуникатив технология нигезендә укыту программасы (1 — 11 нче сыйныфлар). Төзүче – авторлары: Р.З. Хәйдәрова, Р. Л. Малафеева, 2014 ел.
2. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы муниципаль бюджет гомуми белем учреждениясе “Аерым предметларны тирәнтен өйрәнүче Алексеевск 2 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе”нең төп гомуми белем бирү баскычында башлангыч гомуми белем бирү программасы.
3. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы муниципаль бюджет гомуми белем учреждениясе “Аерым предметларны тирәнтен өйрәнүче Алексеевск 2 нче урта гомуми белем мәктәбе”нең 2016-2017 уку елына укыту планы (№1 педсовет протоколы, 31 август 2016 ел).

**Әдәби укуга өйрәтүнең предмет нәтиҗәләре.**

**Сөйләшү** Диалогик сөйләм. 2 нче сыйныфта дәрес вакытының 60-70%ын сөйләшүгә өйрәнү ала. Сөйләм эшчәнлегенең бу төре буенча укучылар түбәндәге күнекмәләргә ия булырга тиешләр:

- сайланган эчтәлек аша әңгәмәдәшең белән контакт урнаштыра, сорау куя, җавап бирә, кире кага, раслый белү;
- дәреслектә бирелгән үрнәк диалогларны сәнгатьле итеп уку, сөйләү һәм охшаш диалоглар төзү, программада күрсәтелгән коммуникатив максатлар буенча әңгәмәдә катнаша алу.

Монологик сөйләм. Сөйләм эшчәнлегенең бу төре буенча укучылар түбәндәге күнекмәләргә ия булырга тиешләр:

- җанлы һәм җансыз предметларны, рәсем, картина эчтәлеклеген сүрәтләп сөйли белү;
- программада күрсәтелгән темалар буенча кечкенә информация бирә белү.

**Ишетеп аңлау (аудирование)**

Аралашу өчен төп шартларның берсе – әңгәмәдәләрнең бер-берсенең сөйләмен аңлавы. 2 нче сыйныфта ишетеп аңларга өйрәтүнең бурычлары түбәндәгеләр:

- нормаль темп белән әйтелгәннең ишетү аша мәгънәсен аңларга, аңлаган турында фикер йөртергә, аралашуда кулана белергә өйрәтү;
- сүзләрне, сүзтезмәләрне, җөмләләрне, грамматик формаларны бер-берсеннән ишетү аша аерырга өйрәтү;
- ишетү хәтеренең күләмен үстерү.

**Сөйләм эшчәнлегенең бу төре буенча укучылар түбәндәге күнекмәләргә ия булырга тиешләр:**

- хәреф-аваз системасын аера, татар теленә хас булган авазларны дөрес әйтеп укый белү;
- дәреслектә уку өчен бирелгән җөмләләрне, текстларны дөрес интонация белән укый белү;
- укыган материалның эчтәлегеннән кирәкле мәгълүматны аерып ала белү;

- кечкенә күләмле шигырьләрне яттан сөйләү;
- укыганда сүзлекләр куллана белү.

Дәреслектә уку техникасын үстерүгә ярдәм итә торган рифмовкалар, җырлар, рифмалаштырылган әкиятләр бирелде. Үзләштерү дәрәҗәсенә карап, укытучы аларны арттыра яки киметә ала.

**Укучыларның әзерлек дәрәҗәсенә таләпләр**

**Әзерлек дәрәҗәсенә таләпләр**
**Шәхси нәтиҗәләр:**
шәхесара һәм мәдәниара аралашуда татар телен куллануга уңай караш булдыру;
татар теленә карата ихтирамлы караш булдыру һәм аны яхшы өйрәнү теләге формалаштыру;
ярдәмчеллек, башка кешеләргә карата кайгыртучанлык хисләрен тәрбияләү.
**Метапредмет(регулятив, коммуникатив, танып- белү) нәтиҗәләре:**
уку хезмәтеңә бәя бирә белү;
эш тәртибен аңлап, уку эшчәнлеген оештыра белү;
укытучының күрсәтмәләрен аңлап үти белү;
дәрескә кирәкле уку-язу әсбапларын әзерли белү, алар белән дөрес эш итә белү;
дәрестә эш урынын мөстәкыйль әзерли белү һәм тәртиптә тоту күнекмәләрен үстерү;
әңгәмәдәшеңең фикерен тыңлый, аралаша белү күнекмәләрен формалаштыру;
рәсем буенча җөмләләр, сораулар төзи белү;
укыганның эчтәләген аңлап, биремнәрне мөстәкыйль үтәү.
**Предмет нәтиҗәләре**
*Диалогик сөйләм*
сайланган эчтәлек аша әңгәмәдәшең белән контакт урнаштыра, сорау куя, җавап бирә, кире кага, раслый белү;
дәреслектә бирелгән үрнәк диалогларны сәнгатьле итеп уку, сөйләү һәм охшаш диалоглар төзү; билгеле бер тема буенча кечкенә диалоглар төзи белү; программада күрсәтелгән коммуникатив максатлар буенча әңгәмәдә катнаша алу;
*Монологик сөйләм*
җанлы һәм җансыз предметларны, рәсем, картина эчтәлеген сурәтләп сөйли белү;
программада күрсәтелгән темалар буенча кечкенә информация бирә белү.
*Тыңлап аңлау*
нормаль темп белән әйтелгәннең мәгънәсен аңларга, аңлаган турында фикер йөртергә, аралашуда куллана белергә өйрәтү;
сүзләрне, сүзтезмәләрне, җөмләләрне, грамматик формаларны бер-берсеннән ишетү аша аерыргаөйрәтү;
ишетү хәтеренең күләмен үстерү.
*Уку*
хәреф-аваз системасын аера, татар теленә хас булган авазларны дөрес әйтеп укый белү;
дәреслектә уку өчен бирелгән җөмләләрне, текстларны дөрес интонация белән укый белү;
укыган материалның эчтәлегеннән кирәкле мәгълүматны аерып ала белү;
кечкенә күләмле шигырьләрне яттан сөйләү;
укыганда сүзлекләр куллана белү.

**II.Укыту предметының эчтәлеге**

**Без мәктәпкә барабыз** Беренче сентябрь. Уку-язу әсбапларының барлыгы, юклыгы, кирәклеге. Уку хезмәте. Беренче сентябрь турында сөйли, укытучыны, дустыңны бәйрәм белән котлый белү. Бер-береңнең ничәнче сыйныфта укуын сорый, җавап бирә белү. Уку-язу әсбапларының барлыгын, юклыгын, кирәклеген хәбәр итә белү (сорау); үзеңә сорап алу, иптәшеңә тәкдим итә белү. Предметларны, саннар кулланып, үзеңә сорый белү.

Бер-береңнең ничәнче сыйныфта укуын сорый һәм җавап бирә белү. Мәктәптәге уку хезмәте турында сорый, сөйли белү, нәрсә эшләгәнне, нәрсә эшләмәгәнне сорый, әйтә белү. Укучының уку хезмәтенә бәя бирә белү.

**Базарда.**

Яшелчәләр. Җиләк-җимешләр. Базарда. Көз билгеләре. Яшелчә, җиләк-җимеш исемнәрен, төсен, тәмен, нәрсә яратуыңны әйтә белү. Базарга барырга чакыра, кем белән барганыңны әйтә белү. Базарда яшелчә, җиләк-җимеш сатып ала белү. Көз билгеләрен, көзне яратканыңны, яратмаганыңны әйтә белү.Урамга уйнарга чакыра белү.

**Мин чисталык яратам**

Шәхси гигиена предметлары.Тән әгъзалары атамалары. Табипта. Шәхси гигиена предметларының исемнәрен, аларны кулланып, нәрсә эшләгәнеңне әйтә, сорый белү. Тән әгъзаларын атый белү.
Табибка кайсы җиреңавыртуын әйтә белү. Авыру кешенең хәлен сорау, аңа дару, чәй тәкъдим итә белү.

**Безнең гаилә**

Безнең гаилә. Татар халык ашлары. Өй хезмәте. Гаилә әгъзаларының исемнәрен атый, гаиләдә кемнәр, ничә кеше барлыгын, кайда эшләгәнен әйтә белү. Татар халык ашларын атый, нинди ашлар пешергәнне белү, бер-береңне табынга чакыра, кыстый, ашаганнан соң рәхмәт әйтә белү. Өй хезмәтендә катнашуыңны әйтә белү.

**Яз килә**

Яз билгеләре. 8 нче Март – әниләр бәйрәме. Яз билгеләрен әйтә белү. Урамга уйнарга чакыра, көннең нинди икәнен сорый, әйтә белү. Бәйрәмдә, нинди бүләк биргәнеңне, кемне котлаганыңны әйтә белү.

**Минем туган ягым** Минем туган ягым. Татарстанның табигате. Татарстан шәһәрләре. Мин авылда яшим. Яз билгеләрен әйтә белү. Урамга уйнарга чакыра, көннең нинди икәнен сорый, әйтә белү. Бәйрәмдә, нинди бүләк биргәнеңне, кемне котлаганыңны әйтә белү. Бер-береңнең яшәү урынын сорый һәм кайда яшәгәнеңне әйтә белү. Татарстан шәһәрләренең, елгаларының атамаларын әйтә белү. Нинди транспортта барганыңны әйтә белү. Кайсы шәһәргә барганны сорый белү. Светофорда нинди төсләр барлыгын әйтә, юл йөрү кагыйдәләрен әйтә белү. Авыл табигате турында сөйли белү. Җәйге уен төрләрен әйтә белү.

**Кибеттә**

Киемнәр кибетендә. Ашамлыклар кибетендә. Кием исемнәрен, бәяләрен сорый, нинди кием яратканыңны әйтә белү. Бер-береңнең киеменә комплимент әйтә белү. Ашамлык исемнәрен, нинди ашамлыклар кирәклеген сорый, әйтә белү. Кибеткә барганыңны һәм нәрсә алганыңны әйтә белү.

**Җәй**

Җәй җитте. Без Сабантуйга барабыз. Җәй көне турында сөйли белү. Каникулны ничек үткәрү турында сөйләшү. Урманда җиләк җыйганыңны әйтә белү.

## III.Төп уку эшчәнлеге төрләре күрсәтелгән тематик планлаштыру.

| № | Дәрес темасы | Уку эшчәнлеге төрләре | Үткәрү вакыты |
|---|---|---|---|
| **Без мәктәпкә барабыз (17 сәг.)** | | | |
| 1 | Яңа уку елы белән! | Сәнгатьле итеп сөйләү, уку. | 2.09 |
| 2 | Х.Гарданов “Исәнмесез, иптәшләр!” | Тәрҗемә итү, текстка таянып сөйләү. | 6.09 |
| 3 | Исәнләшү сүзләре | Тәрҗемә итү, текстка таянып сөйләү, сорауларга җавап бирү. | 9.09 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 4 | Табышмаклар. Текст өстендә эш | Диалог төзү. | 13.09 |
| 5 | Текст “Беренче сентябрь” | Тәрҗемә белән уку. | 16.09 |
| 6 | Сезне бәйрәм белән котлыйм | Тәрҗемә белән уку. | 20.09 |
| 7 | Диалог “Әйдә бергә уйныйбыз” | Диалог уку, парларда уйнау. | 23.09 |
| 8 | Санамышлар | Уку, тәрҗемә итү. | 27.09 |
| 9 | Диалог “Коля нишли?” | Диалог төзү. | 30.09 |
| 10 | Мин Казанга барам | Тәрҗемә итү, текстны сәнгатьле уку. | 4.10 |
| 11 | Диалог “Бәйрәмдә Коля  нишли?” | Тәрҗемә итү, диалог төзү. | 7.10 |
| 12 | Безнең сыйныф | Диалог төзү. | 11.10 |
| 13 | Очты, очты... уены | Диалог төзү. | 14.10 |
| 14 | Әкият “Күмәч” | Сәнгатьле итеп уку, тәрҗемә итү. | 18.10 |
| 15 | Әкият “Күмәч”. Күмәч җыры | Көйгә салып шигырьне җырлау. | 21.10 |
| 16 | Әкият “Күмәч” сәхнәләштерү | Рольләрне матур итеп башкара белү. | 25.10 |
| 17 | “Без мәктәпкә барабыз “ кабатлау дәрес. | Диалог төзи белү. | 28.10 |
| **Базарда (6 сәг.)** | | | |
| 18 | Көз җитте | Лексик берәмлекләрне үзләштерү. | 7.11 |
| 19 | Яшелчәләр | Лексик берәмлекләрне үзләштерү. | 11.11 |
| 20 | Җиләк-җимешләр | Лексик берәмлекләрне үзләштерү. | 14.11 |
| 21 | Текст “Базарда”. Монологик сөйләм үстерү дәресе. | Эчтәлеген аңлый, раслый һәм инкарь итә белү. | 18.11 |
| 22 | Алтын көз | Дөрес  тәрҗемәне табу. | 22.11 |
| 23 | Көз билгеләре | Тәрҗемә итү. | 25.11 |
| **Мин чисталык яратам (6 сәг.)** | | | |
| 24 | Алсу-пөхтә кыз | Тәрҗемә итү. | 28.11 |
| 25 | Мин чисталык яратам | Тәрҗемә итү, текстка таянып сөйләү. | 2.12 |
| 26 | Шәхси гигиена предметлары | Диалог  төзү. | 6.12 |
| 27 | Текст “Марат авырый” | Сәнгатьле уку. | 9.12 |
| 28 | Диалог “Табибта” | Диалог төзү. | 13.12 |
| 29 | Монологик сөйләм “Табибта” | Тәрҗемә итү, текстка таянып сөйләү. | 16.12 |
| **Кыш җитә” (9 сәг.)** | | | |
| 30 | Кыш айлары... | Мөстәкыйль тәрҗемә итү. | 20.12 |
| 31 | Кыш килә | Тулы җаваплар бирү, сораулар төзү. | 23.12 |
| 32 | Яңа ел бәйрәме | Тулы җаваплар бирү, сораулар төзү. | 10.01 |
| 33 | Яңа ел белән | Эчтәлеккә туры килгән диалогларны сайлау, | 13.01 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | текст буенча сораулар төзү. | |
| 34 | Кышкы уеннар | Тулы җаваплар бирү, сораулар төзү. | 17.01 |
| 35 | “Тауда” тексты өстендә эш | Тулы җаваплар бирү, сораулар төзү. | 20.01 |
| 36 | Без кошларга булышабыз | Тулы җаваплар бирү, сораулар төзү. | 24.01 |
| 37 | Кыш көне нәрсәләр була | Тулы җаваплар бирү, сораулар төзү | 27.01 |
| 38 | Кыш темасын кабатлау | Проект эшен башкару. | 31.01 |
| **Безнең гаилә (7 сәг.)** | | | |
| 39 | “Безнең гаилә”тексты өстендә эш | Мөстәкыйль тәрҗемә итү. | 3.02 |
| 40 | “Безнең гаилә” тексты | Тексттан сорауларга җавап табу. | 7.02 |
| 41 | Ш. Маннурның “Яратам”шигыре | Тәрҗемә белән сәнгатьле уку. | 10.02 |
| 42 | “Айдар бездә кунакта” хикәясе | Сөйләмдә тылсымлы сүзләр куллану. | 14.02 |
| 43 | Безгә кунаклар килде | Тексттан сорауларга җавап табу. | 17.02 |
| 44 | “Майны кем ашады?” | Тексттан сорауларга җавап табу. | 21.02 |
| 45 | “Безнең гаилә” темасын кабатлау | Тулы җаваплар бирү, сораулар төзү. | 24.02 |
| **Яз килә (4 сәг.)** | | | |
| 46 | “Яз җитә” шигыре | Көйгә салып җырлау. | 28.02 |
| 47 | 8 нче Март - әниләр бәйрәме | Текстны аңлап уку. | 3.03 |
| 48 | Котлау открыткасы | Тулы җаваплар бирү, сораулар төзү. | 7.03 |
| 49 | “Яз” темасын кабатлау | Төркемнәрдә проект эшен башкару. | 10.03 |
| **Татарстан –минем туган ягым (10 сәг.)** | | | |
| 50 | Мин Татарстанда яшим | Сорау алмашлыкларын гамәли куллану. | 14.03 |
| 51 | Текст “Туган ягым” | “Минем туган ягым “темасына хикәя төзү. | 17.03 |
| 52 | Текст “Туган ягым” | Үзеңнең шәһәрең турында җөмләләр төзү. | 31.03 |
| 53 | Туган ягым тексты өстендә эш | Эчтәлек хаталарын табу. | 4.04 |
| 54 | Татарстан шәһәрләре | Сорау алмашлыкларын гамәли куллану. | 7.04 |
| 55 | Без шәһәрдә яшибез | Сорауларга җавап бирү. | 11.04 |
| 56 | “Юлда”тексты | Хикәягә исем бирү. | 14.04 |
| 57 | Мин авылда яшим | Сорауларга җавап бирү. | 18.04 |
| 58 | Муса Җәлилнең “Әтәч ”шигыре | Сәнгатьле укый белү, көйгә салып җырлау. | 21.04 |
| 59 | “Мин Татарстанда яшим”темасын кабатлау | Тулы җаваплар бирү, сораулар төзү. | 25.04 |
| **Кибеттә (4 сәг.)** | | | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 60 | Киемнәр кибете | Диалогларны рольләргә бүлеп уку. | 28.04 |
| 61 | “Матур киемнәр” тексты өстендә эш | Текст буенча сораулар бирү. | 2.05 |
| 62 | Ашамлыклар кибете | Кушымчаларны дөрес куллану. | 5.05 |
| 63 | Диалог “Кибеттә” | Тулы җаваплар бирү, сораулар төзү. | 9.05 |
| **Җәй (7 сәг.)** | | | |
| 64 | Текст “Җәй җитте” | Текст буенча сораулар бирү. | 12.05 |
| 65 | Б. Рәхмәт “Матур җәй” | Сәнгатьле уку. | 16.05 |
| 66 | М. Газизовтан “Балан” шигыре | Сәнгатьле уку. | 19.05 |
| 67 | Сабантуй бәйрәме | Диалогларны рольләргә бүлеп уку. | 23.05 |
| 68 | Диалог “Сабантуйда”. Йомгаклап кабатлау. | Тулы җаваплар бирү, сораулар төзү. | 26.05 |

Пронумеровано прошнуровано
И скреплено печатью
7 (семь) ______ листов
Учитель татарского языка и
Литературы Сунгатуллина ______

«Алексеевская средняя общеобразовательная школа №2 с углубленным изучением отдельных предметов»
ОГРН 1021605754367
ИНН 1605001185